РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

21.02.2025 № 3

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 08.11.2021 №25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2024 №540-ФЗ Федераль законына, Саба районы Прокуратурасының 11.02.2025 №02-08-02-2025/Прдп106-25-20920031 протестына нигезләнеп Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 №25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Профилактик визит.

3.5.1. Профилактик визит контрольдә тотылучы затның эшчәнлеген башкару урыны буенча инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә йә видео-конференц-элемтә яисә «Инспектор»мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән үткәрелә.

3.5.2. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы зат үз эшчәнлегенә йә аңа караган контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның хәвеф-хәтәр критерийларына туры килүе, хәвеф-хәтәр категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, тәрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән танышу, контроль объектларын хәвеф-хәтәр категориясенә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыю һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

3.5.3. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.

3.5.4. Профилактик визит «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.»;

1.2. 4.1. пунктның 4.1.5. пункчасында икенче абзацында «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга барып тикшерү» сүзләрен «үзара хезмәттәшлексез контроль (күзәтчелек) чараларын» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 4.1. пунктның 4.1.11. пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 4.5. пунктның 4.5.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Документлар буенча тикшерү уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш.

Документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан тикшереп торылучы затка җибәрелгән вакыттан алып шул чорга туктатып тора:

– документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырган вакытка кадәр тапшыру таләпләре;

– контрольдә тотылучы зат тапшырган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында йә бу документлардагы белешмәләрнең контроль (күзәтчелек) органындагы документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында контроль (күзәтчелек) органы мәгълүматларына һәм кирәкле язма күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчыга кадәр аңлату.»;

1.5. 4.5. пунктның 4.5.10. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.6. 4.9.пунктның 4.9.3. пунктчасындагы икенче абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р. Шәмсиев